# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«20» 12 2022ел Яр Чаллы ш. № 4110

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына ярдәм итү чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 3163 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына ярдәм итү максатында, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына, «Россия Федерациясе Хәрби Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы карарына таянып, Тукай муниципаль районы уставының 29 пункты 6 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 07 октябрендәге 26-6-10-В-13621 номерлы хаты, Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 30 сентябрендәге 35 номерлы күрсәтмәсе нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына ярдәм итү чаралары турында» Башкарма комитетның 2022 елның 20 октябрендәге 3163 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның Татарстан

Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына өстәмә ярдәм чаралары турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучы һәм тәрбияләнүче балаларына түбәндәге ярдәм

1) муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларга түләүсез кайнар ризык бирергә:

5-11 сыйныф укучылары өчен – туклану бәясе бер укучыга көненә 45,00 сум;

озайтылган көн төркемнәре өчен – туклану бәясе бер укучыга көненә 25,00 сум.

2) муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркеменә йөрүче балаларның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) кайнар аш өчен түләүдән азат итәргә.

3) муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына) һәм мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренә йөрүче балаларның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итәргә;

4) муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына) һәм мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренә йөрүче балаларның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) өстәмә белем бирү программалары буенча түләүле дәресләр (түгәрәкләр, секцияләр һәм башка шундый дәресләр) өчен түләүдән азат итәргә.».

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пункты 1, 2, 4 пунктчасында күрсәтелгән балалар укый торган муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

1) әти-әниләрдән (законлы вәкилләрдән), туу турында таныклык күчермәсен һәм хәрби комиссариаттан раслаучы документны теркәп, түләүсез кайнар ризык бирү турында гаризаларны кабул итү эшен оештырырга;

2) укучыларны тукландыруны оештырырга;

3) кирәк булганда, муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең махсус медицина күрсәткечләре буенча өйдә белем алучы укучыларына туклану продуктлары җыелмалары бирүне оештырырга;

4) әлеге карарда күрсәтелгән ярдәм чараларын күрсәтү максатында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия

Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәм мәктәпкәчә белем бирүнең төп программасын гамәлгә ашыручы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә укучы балалары санына даими мониторинг алып барырга;

5) балаларга өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча дәресләргә (түгәрәкләргә, секцияләргә һәм башка шундый дәресләргә) түләүсез йөрү мөмкинлеген бирергә.».

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның 1 пункты 3, 4 пунктчаларында күрсәтелгән балалар йөри торган муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре һәм мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

1) әти-әниләрдән (законлы вәкилләрдән), туу турында таныклык күчермәсен һәм хәрби комиссариаттан раслаучы документны теркәп, баланы карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү турында гаризалар кабул итү эшен оештырырга;

2) әлеге пунктта күрсәтелгән балаларны карау һәм тәрбияләүне оештырырга;

3) әлеге карарда күрсәтелгән ярдәм чараларын күрсәтү максатында, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә укучы балалары санына даими мониторинг алып барырга;

4) балаларга өстәмә белем бирү программалары буенча дәресләргә (түгәрәкләргә, секцияләргә һәм башка шундый дәресләргә) түләүсез йөрү мөмкинлеген бирергә.».

2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) 3 эш көне дәвамында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы финанс бюджет палатасына мәгариф учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә

каралган акча средстволарын үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәле 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин